ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04 март 2022ел № 1120

Башкарма комитетның «2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәрендә халыкны наркотизацияләүне профилактикалау» муниципаль программасы турында» 2019 елның 30 октябрендәге 5595 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәрендә халыкны наркотизацияләүне профилактикалау» муниципаль программасы турында» 2019 елның 30 октябрендәге 5595 номерлы карарына (Башкарма комитетның 2020 елның 16 мартындагы 1231 номерлы, 2020 елның 2 ноябрендәге 5742 номерлы, 2021 елның 30 мартындагы 2155 номерлы, 2021 елның 1 октябрендәге 6435 номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә «2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәрендә халыкны наркотизацияләүне профилактикалау» муниципаль программасын тормышка ашыру буенча чараларны финанслауны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетында «Яшьләр сәясәте һәм балаларны сәламәтләндерү» 07.07 бүлеге (бүлекчәсе) буенча каралган акчалар хисабына 2020 елда – 355,3 мең сум, 2021 елда – 378,8 мең сум, 2022 елда – 400,0 мең сум күләмендә тәэмин итәргә.»;

2) «2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәрендә халыкны наркотизацияләүне профилактикалау» муниципаль программасында:

- 1 бүлектә «Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары | Финанслау чыганаклары | Программаны тормышка ашыру еллары | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 2020 ел (мең сум) | 2021 ел (мең сум) | 2022 ел (мең сум) | Тормышка ашыру чорында барлыгы |
| | Муниципаль бюджет | 355,3 | 378,8 | 400,0 | 1134,1 |
| | Федераль бюджет | - | - | - | - |
| | Республика бюджеты | - | - | - | - |
| | Башка чыганаклар | - | - | - | - |
| | Барлыгы | 355,3 | 378,8 | 400,0 | 1134,1»; |

- 5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5 бүлек. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

2020-2022 елларга программаны финанслау күләме 1134,1 мең сум тәшкил итә.

Программаны финанслау чыганагы булып Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты тора.

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең бюджет акчалары:

Чор өчен барлыгы 1134,1 мең сум, шул исәптән программаны тормышка ашыру еллары буенча:

2020 ел – 355,3 мең сум, 2021 ел – 378,8 мең сум, 2022 ел – 400,0 мең сум.»;

- 1 нче кушымтаны кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2022 елның 4 мартындагы
1120 номерлы карарына
кушымта

«2020-2022 елларга
Яр Чаллы шәһәрендә халыкны
наркотизацияләүне профилактикалау»
муниципаль программасына
1 нче кушымта

«2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәрендә халыкны наркотизацияләүне профилактикалау» муниципаль программасының максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм чаралар буенча финанслау

| Т/с | Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | Финанслау (мең сум) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2019 ел база | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2020 ел мең сум | 2021 ел мең сум | 2022 ел мең сум |
| Программаның максаты: Сәламәт яшәү стилен формалаштыруга юнәлдерелгән комплекслы чаралар системасын, Яр Чаллы шәһәре халкы арасында психоактив матдәләр куллану һәм таратуга комачаулаучы үз-үзеңне тоту стратегияләрен һәм шәхес ресурсларын булдыру | | | | | | | | | Муниципаль бюджет | | |
| Программа буенча профилактика чараларына җәлеп ителгән 14 яшьтән 30 яшькә кадәрге яшүсмерләр һәм яшьләр өлеше, әлеге яшь төркеменең гомуми санынннан, процент, % | | | | | 67,5 | 76,5 | 76,5 | 76,5 | - | - | - |
| 1 бурыч. Шәһәр халкы арасында наркоманияне профилактикалауга мәгълүмат-пропаганда ярдәме күрсәтүне тәэмин итү. | | | | | | | | | | | |
| 1. | «СФЕРА» мәгълүмати-медиа киңлеге» проектын тормышка ашыру | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, «Диалог» психологик-педагогик ярдәм үзәге» МБУ | Ел саен | Мәгълүмати материаллар саны, берәмлек | 1000 | 2000 | 2000 | 2000 | 15,0 | 46,5 | 50,0 |

| 2 бурыч. Халыкның төрле максатчан төркемнәре өчен наркотикларга каршы профилактика чаралары оештыру һәм үткәрү | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2. | «Шәхси стратегияләр коучы» проектын тормышка ашыру | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, «Диалог» балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм үзәге» МБУ | Ел саен | Оештырылган һәм үткәрелгән чаралар саны, берәмлек | - | 10 | 10 | 10 | 39,5 | 31,2 | 40,0 |
| | | | | Чараларда катнашкан яшьләр саны, кеше | - | 200 | 200 | 200 | | | |
| 3. | «Тормыш ритмында» наркотикларга каршы профилактика чаралары шәһәр конкурсы үткәрү | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, «Диалог» балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм үзәге» МБУ | Ел саен | Конкурс кысаларында үткәрелгән профилактика чараларының саны, берәмлек | 15 | 15 | 20 | 20 | 49,3 | 43,9 | 50,0 |
| | | | | Конкурс чараларына җәлеп ителгән яшьләр саны, кеше | - | - | 1 500 | 1 500 | | | |
| 4. | «#СКРИН» наркотикларга каршы платформа» яшьләр активлыгы шәһәр конкурсын үткәрү | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, «Диалог» балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм үзәге» МБУ | Ел саен | Конкурс кысаларында үткәрелгән профилактика чараларының саны, берәмлек | - | 10 | 10 | 10 | 37,5 | 31,2 | 40,0 |
| | | | | Чараларда, конкурста катнашкан яшьләр саны, кеше | - | 100 | 100 | 100 | | | |
| 5. | «YOUность» (Юность) профилактика проектын тормышка ашыру | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, «Диалог» балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм үзәге» МБУ | Ел саен | Үткәрелгән чаралар саны, берәмлек | - | 10 | 10 | 10 | 17,7 | 19,2 | 20,0 |
| | | | | Чараларда катнашкан яшьләр саны, кеше | - | 100 | 100 | 100 | | | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 6. | Яр Чаллы шәһәренең балалар һәм яшьләр берләшмәләре арасында «СпАРТиан уеннары» турниры» спорт-профилактика проекты үткәрү | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, «Орион» ЯҮ» МАУ | Ел саен | Үткәрелгән уеннар саны, берәмлек | - | 5 | 5 | 5 | 25,0 | 24,0 | 25,0 |
| | | | | Проектта катнашкан яшьләр саны, кеше | - | - | 300 | 300 | | | |
| 7. | Наркотикларга каршы «Dance & health» («Бию һәм сәламәтлек») проектын тормышка ашыру | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, «Шатлык» ЯҮ» МАУ | Ел саен | Проектта катнашкан яшьләр саны, кеше | - | 120 | 120 | 120 | 29,9 | 30,0 | 30,0 |
| | | | | Үткәрелгән чаралар саны, берәмлек | - | - | 5 | 5 | | | |
| 8. | «Яр Чаллы шәһәре эшләүче яшьләрнең шәһәр спартакиадасы» спорт-профилактика проектын тормышка ашыру | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, «Заман» ЯҮ» МАУ | Ел саен | Катнашкан оешмалар саны, берәмлек | - | 30 | 30 | 30 | 20,0 | 17,2 | 20,0 |
| | | | | Проектта катнашкан яшьләр саны, кеше | - | - | 1000 | 1000 | | | |
| 9. | Яшүсмерләр һәм яшьләр арасында «Сәламәт Яшәү Рәвеше Территориясе» профилактика чарасы үткәрү | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, «Яшүсмер» яшәү урыны буенча Я(Я)КҮ» МАУ | Ел саен | Катнашкан клублар саны, берәмлек | - | 15 | 15 | 15 | 31,4 | 34,0 | 35,0 |
| | | | | Катнашкан яшьләр саны, кеше | | - | 75 | 75 | | | |
| 10. | Яшүсмерләр-яшьләр арасында наркотикларга каршы «Киләчәккә юл» квесты үткәрү | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, «Яшүсмер» яшәү урыны буенча Я(Я)КҮ» МАУ | Ел саен | Катнашкан клублар саны, берәмлек | - | 15 | 15 | 15 | 30,0 | 30,0 | 30,0 |
| | | | | Катнашкан яшьләр саны, кеше | - | - | 75 | 75 | | | |
| 11. | «Сәламәт принцип» профилактика чаралары комплексын үткәрү | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, «Нур» ЯҮ» МАУ | Ел саен | Үткәрелгән чаралар саны, берәмлек | - | 8 | 8 | 8 | 30,0 | 29,8 | 30,0 |
| | | | | Чараларда катнашкан яшьләр саны, кеше | | | 90 | 90 | | | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 12. | «Синең Территория» шәһәр яшьләр профилактика проектын тормышка ашыру | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе,<br>«Нур» ЯҮ» МАУ | Ел саен | Үткәрелгән чаралар саны, берәмлек | - | 10 | 10 | 10 | 30,0 | 29,9 | 30,0 |
| | | | | Проектта катнашкан яшьләр саны, кеше | - | - | 100 | 100 | | | |
| 13. | Интернет челтәрендә наркотикларга каршы «#Ачык диалог» мәгълүмат мәйданчыгы» онлайн мәгълүмати-агарту чаралары үткәрү | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе,<br>«Диалог» балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм үзәге» МБУ | Ел саен | Үткәрелгән чаралар саны, берәмлек | - | - | 3 | - | - | 11,9 | - |
| | | | | Чараларда катнашкан яшьләр саны, кеше | - | - | 100 | - | | | |
| Барлыгы: | | | | | | | | | 355,3 | 378,8 | 400,0 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы — Н.И. Галиева